**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4012**
**15.06.2021**

Башкарма комитетның «Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибе, махсус билгеләнгән урыннар һәм биналар исемлеге турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 7300 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.25 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибе, махсус билгеләнгән урыннар һәм биналар исемлеге турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 7300 номерлы карарына, 3 нче кушымтаны әлеге карарга кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 15 июнендәге
4012 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2017 елның 27 ноябрендәге
7300 номерлы карарына
3 нче кушымта

Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасы,
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Шәһәр Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен
түләүсез нигездә бирелә торган биналар
исемлеге

| № т/б | Оешманың исеме | Адрес | Учреждение җитәкчесе | Залның сыйдырышлыгы (урыннар саны) | Вакыт |
|---|---|---|---|---|---|
| Үзәк районы | | | | | |
| 1 | Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 59 йорт | Ковальчук Гөлчәчәк Хак кызы 39-94-85 | 100 | учреждение белән килешү буенча |
| Комсомол районы | | | | | |
| 2 | Яр Чаллы шәһәренең «15 нче балалар иҗат йорты» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Столбовая урамы, 53 йорт | Грачева Светлана Николаевна 71-25-20 | 100 | учреждение белән килешү буенча |
| 3 | Яр Чаллы шәһәренең «Эврика» шәһәр мәдәният үзәге» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Чулман проспекты, 6 йорт | Галиева Ландыш Фирдәвис кызы 36-75-26 | 150 | учреждение белән килешү буенча |
| 4 | «39 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Нур Баян урамы, 10 йорт | Галиев Азат Таһир улы 49-31-40 | 650 | учреждение белән килешү буенча |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Автозавод районы | | | | | |
| 5 | Яр Чаллы шәһәренең «КАМАЗ» мәдәният сарае» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 87/22 йорт | Динушова Динара Рәфыйк кызы 54-34-45 | 168 | учреждение белән килешү буенча |
| 6 | Яр Чаллы шәһәренең «Эврика» шәһәр мәдәният үзәге» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе | Яр Чаллы шәһәре, Тенистая урамы, 1 йорт | Галиева Ландыш Фирдәвис кызы 36-75-26 | 300 | учреждение белән килешү буенча |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева